| | |
|---|---|
| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.06.2024 Казан ш. № 01-05/157-пр

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2022 елның 17 июнендәге 01-05/142-пр номерлы боерыгы белән расланган Аттракционнарны дәүләт теркәве буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүне камилләштерү максатларында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2022 елның 17 июнендәге 01-05/142-пр номерлы боерыгы белән расланган Аттракционнарны дәүләт теркәве буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

2.6.1 пунктның «л» пунктчасы түбәндәге редакциядә бирергә:

«л) аттракционның Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Аттракционнарның техник торышына һәм эксплуатациясенә карата таләпләр исемлегенә туры килүен раслый торган, аттракционны монтажлап (җыеп, урнаштырып) бетергәннән соң махсус оешма тарафыннан бирелгән, бирелгән көненнән башлап 12 айдан артык вакыт узмаган аттракционның техник торышын (техник тикшерүне) бәяләү акты (Евразия икътисадый берлегенең «Аттракционнарның куркынычсызлыгы турында» техник регламенты үз көченә кергән көнгә кадәр әзерләнгән һәм файдалануга кертелгән аттракционнар өчен));».

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче А.Ш. Борһанов